СОВЕТ НИЖНЕШАНДЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1, с. Зюри,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422153

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШҮЛӘҢГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 1 нче йорт, Җөри авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422153

тел.(факс): (85563) 3-87-31; e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
20 февраль 2023 ел.

Карар
№2-20

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге №1-32 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Территорияләрнең комплекслы үсешен тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге №494-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләңгер авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турында»1-32 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Кушымтаның 12 статьядагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3 пунктының 3.1 һәм 3.2 өлешләрендә билгеләнгән очраклардан тыш, җирлекләрнең генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә».

1.2. Кушымтаның 12 статьясындагы 2 абзацындагы «, шәһәр округы генераль планнары» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башлыгы Е.М.Михайловага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Шүләңгер авыл җирлеге
Советы рәисе, җирлек башлыгы Е.М.Михайлова